КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2021 ел, 30 декабрь г.Казань № 1338

Татарстан Республикасы территориясендә алкоголь продукциясен ваклап сату һәм җәмәгать туклануы хезмәтләрен күрсәткәндә алкоголь продукциясен ваклап сату рөхсәт ителмәгән югары куркынычлык чыганаклары урнашу урыннарын билгеләү турында

«Этил спирты, алкогольле һәм спиртлы продукция җитештерүне һәм аларның әйләнешен дәүләт җайга салуы турында һәм алкоголь продукциясен куллануны (эчүне) чикләү хакында» 1995 елның 22 ноябрендәге 171-ФЗ номерлы Федераль законның 16 статьясындагы 2 пунктының 7 пунктчасы, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Россия Федерациясе субъектлары дәүләт хакимияте органнары тарафыннан алкоголь продукциясен ваклап сату һәм җәмәгать туклануы хезмәтләрен күрсәткәндә алкоголь продукциясен ваклап сату рөхсәт ителми торган югары куркынычлык чыганаклары урнашу урыннарын билгеләү тәртибе турында» 2020 елның 23 декабрендәге 2219 номерлы карары нигезендә Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы территориясендә алкоголь продукциясен ваклап сату һәм җәмәгать туклануы хезмәтләрен күрсәткәндә алкоголь продукциясен ваклап сату рөхсәт ителмәгән, «Куркыныч җитештерү объектларының сәнәгать куркынычсызлыгы турында» 1997 елның 21 июлендәге 116-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә билгеләнгән, сәнәгать куркынычсызлыгы декларациясен мәҗбүри эшләү каралган куркыныч җитештерү объектлары чикләрендә урнашкан югары куркынычлык чыганаклары урнашу урыннарын кушымта нигезендә билгеләргә.

2. Түбәндәгеләр үз көчен югалткан дип танырга:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасында халык арасында алкогольле продукциядән, сырадан, тәмәкедән явыз ниаттә файдалануны киметү һәм сәламәт яшәү рәвешен формалаштыру буенча өстәмә чаралар турында» 2010 ел, 29 октябрь, 867 нче карары;

«Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасында халык арасында алкогольле продукциядән, сырадан, тәмәкедән явыз нияттә файдалануны киметү һәм сәламәт яшәү рәвешен формалаштыру буенча өстәмә чаралар турында» 2010 ел, 29 октябрь, 867 нче карарына үзгәрешләр кертү хакында» Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2011 ел, 29 июнь, 525 нче;

«Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының кайбер карарларына үзгәрешләр кертү турында» Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2011 ел, 24 сентябрь, 788 нче карары;

«Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының кайбер карарларына үзгәрешләр кертү турында» Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2013 ел, 27 май, 354 нче карары;

«Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасында халык арасында алкогольле продукциядән, сырадан, тәмәкедән явыз нияттә файдалануны киметү һәм сәламәт яшәү рәвешен формалаштыру буенча өстәмә чаралар турында» 2010 ел, 29 октябрь, 867 нче карарына үзгәрешләр кертү хакында» Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2021 ел, 19 июль, 596 нчы.

3. Бу карарның үтәлешен тикшерүдә тотуны Татарстан Республикасы Премьер-министры урынбасары – Татарстан Республикасы сәнәгать һәм сәүдә министры А.Ә.Кәримовка йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин